**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 ноябрь № 871

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 март, 128 нче; 2015 ел, 20 апрель, 269 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 398 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 683 нче; 2015 ел, 26 сентябрь, 711 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

21 нче пунктның 3 графасында «0,89» саннарын «1,0» саннарына алмаштырырга;

82 нче пунктның 2 графасында «П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте» ДБҺББУ» сүзләрен «П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте» ДАҺББУ» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\871.doc